**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Верхнестярлинского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

ул. Советская, д32г , село Верхнее Стярле,
Азнакаевского муниципального района, 423314
Тел. (факс) (85592) 42618
VSt.Azn @tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Югары Стэрле авыл җирлеге башкарма комитеты**

Совет урамы, 32г, Югары Стэрле авылы
Азнакай муниципаль районы, 423314
Тел. (факс) (85592) 42618
VSt. .Azn @tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

От «2» август 2019 ел № 28

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 24.03.2004 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Югары Стәрле авыл җирлеге Уставы нигезендә

Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар чыгара:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatar.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Л.С.Сабирҗанова

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стэрле авыл җирлеге Башкарма комитет карарына кушымта 2 август.2019 №28

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Югары Стәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар 31 мартка кадәр үзара салым акчаларын җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның толларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, түли.

3. Аерым категория гражданнар өчен:

а) 2 төркем инвалидлар,

б) 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар,

в) күп балалы гаиләләр,

түләү күләме җирле референдум (гражданнар җыенында) карарында билгеләнгән сумманың 50 (илле) процентын тәшкил итә.

4. Бер тапкыр бирелә торган түләү турында хәбәрнамә (уведомление) бланкы, җирлек сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән, гражданнарга җиткерелә: http://aznakayevo.tatarstan.ru шулай ук почта элемтәсе аша имза яисә юллама тапшыру юлы белән (әлеге Тәртипкә кушымта).

Хәбәрнамәдә (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

6. Гражданнардан кергән үзара салым акчалары Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар аша, почта күчерүләрен (исәп-хисап оешмаларын) башкаруга, Югары Стәрле авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша бирелә. https://uslugi.tatarstan.ru/

8. Түләү фактын раслап, керемле касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

9. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы “Югары Стәрле авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге торак пукнктларында
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибенә кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлеге
бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № ______________

Түләүченең Ф.И.О.
_____________________________________________________________________
Адрес: ____________________________________________________________
____________________________________________________нигезендә
Сезгә ________ кадәр үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләргә кирәк.
______________ сум
реквизитлар:______________________________________________
алучы банкы БИК _____________________________________
Сч. № __________________________________
Сч. № ____________________________________________
ИНН _____________________________________________
КПП ________________________________________________
КБК ______________________ ОКАТО _____________________
Түләүнең билгеләмәсе ________________________________________
Җитәкче__________________
М.П. (имза) (расшифровка)

**- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисеп алу линиясе - - - - - - - - - - - - - - -**

Хәбәрнамә (Уведомление) № __________________
бюджетка үзара салым буенча бер тапкыр түләү түләү турында
________________________
*(муниципаль берәмлек исеме)*
________________ сум
Түләүченең Ф.И.О. _____________________________________________________
Адресы:
_____________________________________________________________________
«__» ______________ 20__ г. _________________________________________
(түләүче имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, өземтә (корешок)* Югары Стәрле *авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала*